**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ          КАРАР

«25» гыйнвар, 2023 ел          № 58

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 22 мартындагы 188 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 мартындагы 1882 номерлы карары белән расланган административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәнең формаль-логик тикшерүе гариза бирүченең һәр кырын электрон формадагы кырны тутыру процессында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан тутырылган электрон рәвештәге кырның корректлы булмаса, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән сорауның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.»;

- торак урыннарга мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты текстында тиешле

килешләрдә «Россия Федерациясе пенсия фонды» сүзләрен тиешле килешләрдә «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында http://pestreci.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе В.И.Никитин